**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 21 » 07 2021 № 228

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2016 ел, 22 июль, 373 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 2011 ел, 08 декабрь, №76 карары белән расланган Аксубай муниципаль районының Финанс бюджет палатасы турындагы Нигезләмә, Ревизияләр һәм тикшерүләр үткәрү өлкәсендә хокук мөнәсәбәтләрен регламентлаучы Россия Федерациясенең башка хокукый актлары, аларның нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чаралар күрү нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2016 ел, 22 июль, №373 карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Гомуми нигезләмәләр» беренче бүлегендәге 1.12. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.12. Эчке финанс тикшерүенең муниципаль функциясен үтәү нәтиҗәләрен тасвирлау.

1.12.1. Эчке муниципаль финанс тикшерүе муниципаль функциясен үтәү нәтиҗәләре буенча төзелә:

- күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү таныклыгы (1 нче кушымта);
- контроль гамәлләр тәмамлану турында белешмә (2 нче кушымта);
- тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелә торган актлар (3 нче кушымта), тикшерү акты (4 нче кушымта), тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмә (5

нче кушымта), тикшерү чаралары барышында алынган экспертизалар (тикшеренүләр, фото, видео - һәм аудиоматериаллар);

- Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр (6 нчы кушымта);

- Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы бүтән норматив хокукый актларны карау өчен мәҗбүри булган белешмәләр һәм аларны бетерү, шулай ук мондый бозуларның сәбәпләрен һәм шартларын бетерү буенча чаралар кабул итү турында таләпләр (7 нче кушымта);

- Аксубай муниципаль районына китерелгән зыянны каплату турында күрсәтмәне үтәмәгән очракта, вазыйфаи затлары тарафыннан Аксубай муниципаль районына китерелгән зыянны каплау турында Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет-хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны бозган өчен судка җибәрелгән контроль объектының вазыйфаи затлары тарафыннан салынган зыянны каплау турында дәгъва гаризасы;

- административ хокук бозу турында беркетмә (8 нче кушымта);

- күчмә тикшерү (ревизия) уздырганда соралган документларны (мәгълүматны, материалларны) тапшырмау (вакытында тапшырмау) факты турында акт (9 нчы кушымта);

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында хәбәрнамә (10 нчы кушымта);

- хокук бозу билгеләре турында таныклаучы шартлар һәм фактлар булган, аларны ачыклаган очракта, башка дәүләт органына (вазыйфаи затка), мондый бозуларны карау компетенциясенә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карау өчен җибәрелгән материаллар.».

Регламентка 3, 5, 6, 7 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә һәм регламентны әлеге карарның 10 нчы кушымта белән тулыландырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю. Зайцев